**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада сораулары**
**(мәктәп туры, 2015-2016 уку елы) 6 нчы сыйныф**
**Башкару вакыты – 1 сәгать (60 минут)**
**Гомуми балл - 100**

## I. Әдәбият теориясенә караган биремнәр.

1. Әлеге билгеләмәгә туры килгән теоретик төшенчәләрне языгыз. ( 10 балл)

Дөньяның килеп чыгышы, кешеләрнең барлыкка килүе, каһарманнарның батырлыгы хакында бик борынгы сөйләкләр .... дип атала.

Әдәби әсәрдә катлаулы, каршылыклы вакыйгалар, характерлар мисалында образлы фикер йөртү логикасына нигезләнеп куелган мәсьәлә ... дип атала.

2. Алдагы сыйныфта үткәннәрегезне дә искә төшереп, халык авыз иҗатының төп жанрларын билгеләгез. Аларны берләштергән нинди уртак сыйфатларны әйтә аласыз? (20 балл)

## II. Әдәби иҗатка караган биремнәр.

1. Әлеге өзекләр алынган әсәрләрнең исемнәрен һәм авторларын билгеләгез: (10 балл)

*“Көннәрдән бер көнне боларның игезәк ир балалары булды.”*
*“Менә күптән көтелгән көн килеп җитте. Бүген Сабан туе!”*.
*“Эт эчәгесе куркынып кына тишелеп чыкты.*”

2. Беренче баганада күрсәтелгән образларны икенче баганадагы әсәрдән алынган аңа бәйле өзекләр белән тәңгәлләштерегез.(10 балл)

| | |
|---|---|
| Әбелхарис | Әнә күрегез: ул ничек көмеш тавышы белән яңгыратып кешни! |
| Закир | ...Багдад шәһәренә барып, кырык агач кисеп алып кайтты. “Барыгыз да кешеләр булыгыз”, - диде. |
| Алмачуар | Шуннан соң дөньяда һичбер малга, һичбер әйбергә күңелем дә, күзем дә төшмәде: һичбер нәрсәне сөя алмадым. |

3. Үзегез теләгән ике әсәрнең төп геройларына чагыштырма характеристика бирегез.(20 балл)

## III. Иҗади эш. (30 балл)

*1. Җиде кат уйла...* мәкален дәвам итеп бетерегез һәм шуңатаянып, үз тормышыгыздагы берәр вакыйга хакында кечкенә генә хикәя языгыз.